**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 13 гыйнвар | № 4

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына «Ярдәмче программалар киселешендә «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын финанслау күләме» 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы, 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы, 2015 ел, 30 октябрь, 821 нче, 2016 ел, 12 апрель, 215 нче, 2016 ел, 22 сентябрь, 674 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына «Ярдәмче программалар киселешендә «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын финанслау күләме» 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«10 нчы ярдәмче программа. «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру системасын камилләштерү» – барлыгы,» юлында «41 800 440,6» саннарын «41 607 121,5» саннарына, «34 927 762,0» саннарын – «34 734 442,9» саннарына алмаштырырга;

10 нчы ярдәмче программаның «билгеләнгән тәртиптә җәлеп итү планлаштырылган ММИ акчасы» юлында «19 486 270,4» саннарын «19 292 951,3» саннарына алмаштырырга;

«Билгеләнгән тәртиптә җәлеп итү планлаштырылган ММИ акчасы» соңгы юлында «170 972 748,1» саннарын «170 779 429,0» саннарына, «19 486 270,4» саннарын «19 292 951,3» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\4.docx